МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.05.2016 г. Казань № под-1018/16

**2016 елда татарстан республикасында бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «уңышлы мәктәп» гранты турында**

Татарстан Республикасында мәгариф эшчәнлегендә тотрыклы рәвештә югары нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итүче дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына белем бирү сыйфатын күтәрүне стимуллаштыру һәм ярдәм итү, үстерүгә юнәлтелгән социомәдәни мохит булдыру, укыту-тәрбия процессын оештыру өлешендә уңай тәҗрибәне тарату, мәктәпләрнең педагогик коллективын һөнәри үстерү максатларында боерык бирәм:

1. 2016 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын гамәлгә куярга.

2. 2016 елның 15 июненнән 16 июленә кадәрге чорда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын алу өчен конкурс (алга таба - Конкурс) оештырырга һәм үткәрергә.

3. Расларга (кушымта итеп бирелә):

3.1. 2016 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын алу өчен конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча чаралар планын;

3.2. 2016 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын алу өчен конкурсны оештыру һәм аны үткәрүнең календарь планын;

3.3. 2016 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» гранты турында нигезләмәне.

4. Структур бүлекчәләр җитәкчеләренә һәм чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларга әлеге боерыкның 3.1 һәм 3.2 пунктлары белән расланган планнар үтәлешен тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенә (Р.Р.Бәдриева) Конкурсның төбәк этабын оештыру-методик озата баруны тәэмин итәргә.

6. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г.Ф.Гатиятуллина) Конкурсны оештыру һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

7. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр Э.Н.ФӘТТАХОВ

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 25 маендагы под-1018/16 номерлы боерыгы белән расланган

**2016 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БӨТЕНРОССИЯ КОНКУРСЫНЫҢ ТӨБӘК ЭТАБЫ КЫСАЛАРЫНДА «УҢЫШЛЫ МӘКТӘП» ГРАНТЫН АЛУ ӨЧЕН КОНКУРСКА ӘЗЕРЛЕК ҺӘМ АНЫ ҮТКӘРҮ БУЕНЧА ЧАРАЛАР ПЛАНЫ**

| NN | Чара | Җаваплылар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Конкурска әзерлек һәм аны үткәрү белән гомуми җитәкчелек | Мөхәммәтов И.Р.;<br>Федорова Т.Т. |
| 2. | Конкурсны үткәрү буенча смета төзү | Гатиятуллина Г.Ф.;<br>Имамова Г.К. |
| 3. | Конкурсны үткәрү программасын төзү | Федорова Т.Т.;<br>Әхмәрова Г.Р. |
| 4. | Конкурс сынаулары расписаниесен төзү | Бәдриева Р.Р.;<br>Әхмәрова Г.Р.;<br>Мартьянова О.В. |
| 5. | Хисап комиссиясе эшен оештыру | Федорова Т.Т.;<br>Әхмәрова Г.Р.;<br>Мартьянова О.В.;<br>Любина С.Б. |
| 6. | Конкурсны үткәрү көннәрендә фото һәм видеога төшерү. Конкурсның барышын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештыру. | Мөхәммәтова А.Д. |
| 7. | Жюри эшен координацияләү һәм тәэмин итү | Федорова Т.Т.;<br>Бәдриева Р.Р.;<br>Әхмәрова Г.Р. |
| 8. | Конкурсны үткәрүне оргтехника белән тәэмин итү | Кравцов А.А. |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 25 маендагы под-1018/16 номерлы боерыгы белән расланды

**2016 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БӨТЕНРОССИЯ КОНКУРСЫНЫҢ ТӨБӘК ЭТАБЫ КЫСАЛАРЫНДА «УҢЫШЛЫ МӘКТӘП» ГРАНТЫН АЛУ ӨЧЕН КОНКУРСНЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮНЕҢ КАЛЕНДАРЬ ПЛАНЫ**

| N п/п | Чара | Башкару вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Конкурсны оештыру һәм үткәрү мәсьәләсе буенча оештыру комитеты киңәшмәсе | 2016 елның феврале | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы) |
| 2. | Директорлар советы президиумында Конкурс шартларын тикшерү | 2016 елның феврале | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 3. | Укыту-методик эш буенча директорлар урынбасарлары белән киңәшмә | 2016 елның марты | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 4. | Муниципаль районнар башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләр) башлыклары белән киңәшмә | 2016 елның марты | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 5. | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (алга таба – «ТР мәгарифне үстерү институты» | 2016 елның марты | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | оешмасы) сайтларында Конкурс турында норматив-методик материаллар урнаштыру | | |
| 6. | «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасы сайтында Конкурста катнашуга дәгъва кылучыларны теркәү | 2016 елның 15 июненә кадәр | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 7. | Грантка тапшырылган материалларны бәяләү (Конкурсның читтән торып үткәрелә торган беренче этабы) | 2016 елның 20-24 июне | «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасы, эксперт комиссиясе |
| 8. | Икенче турыдан-туры этапта катнашу өчен грантка дәгъва кылучылар исемлеген бастырып чыгару | 2016 елның 24 июне | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасы |
| 9. | Апелляцияләр кабул итү һәм аларны карап тикшерү | 2016 елның 27 июненән 1 июленә кадәр | «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасы, Республика конкурс комиссиясе |
| 10. | Конкурсның икенче турыдан-туры этабы | 2016 елның 4-9 июле | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасы |
| 11. | Грант алучылар исемлеген формалаштыру | 2016 елның 11-15 июле | «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасы, Республика конкурс комиссиясе |
| 12. | Грант алучыларның расланылган | 2016 елның 20 | ТР Мәгариф һәм фән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | исемлеген сайтка урнаштыру | июле | министрлыгы |

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 25 маендагы под-1018/16 номерлы боерыгы белән расланды

# 2016 ЕЛДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БӨТЕНРОССИЯ КОНКУРСЫНЫҢ ТӨБӘК ЭТАБЫ КЫСАЛАРЫНДА «УҢЫШЛЫ МӘКТӘП» ГРАНТЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2016 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» гранты (алга таба – Грант) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

Чарада катнашучылар булып грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) һәм грант алучы тора.

Грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) – грант бирү вәкаләтләрен тормышка ашыручы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы.

Грантка дәгъва кылучы – гомуми белем бирү мәгариф программаларын тормышка ашыручы, кимендә өч тапкыр 11 сыйныфны чыгарган (соңгы өч елда) Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмасы.

Грант алучы – бу Нигезләмәдә билгеләнгән критерийләргә һәм таләпләргә туры килеп, 1 дән 21гә кадәр урын алган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмасы.

Грант педагогик коллективны һөнәри үстерүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен Грант алучыларга акчалата бүләк сыйфатында бер тапкыр бирелә торган түләү булып тора:

1дән 10га кадәр урын алган ун гомуми белем бирү оешмасына – 2 000 000 (икешәр миллион) сум күләмендә;

11дән 21гә кадәр урын алган унбер гомуми белем бирү оешмасына – 1 000 000 (берәр миллион) сум күләмендә.

1.2. Грантны алучыларны конкурс нигезендә сайлап алуның (алга таба – конкурс нигезендә сайлап алу) максаты – Татарстан Республикасында мәгариф эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешүне тотрыклы тәэмин итүче дәүләти һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының, аларның педагогика коллективларының белем бирү сыйфатын яхшыртуга һәм аларга ярдәм итүгә, үстерүгә юнәлтелгән социо-мәдәни мохит булдыруга, укыту-тәрбия процессын оештыру ягыннан оешмаларның уңай эш тәҗрибәсен таратуга, мәктәпләрнең педагогик коллективларының һөнәри яктан үсешенә этәргеч бирү.

1.3. Конкурс нигезендә сайлап алуның бурычы булып белем бирү эшчәнлегендә, үстерүгә юнәлтелгән иҗади һәм һөнәри педагогик мохит булдыруда тотрыклы рәвештә югары нәтиҗәләргә ирешүне тәэмин итеп килүче мәгариф оешмаларын ачыклау һәм аларны бүләкләү тора.

1.4. 2016 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын алуга конкурс (алга таба – Конкурс) – гавәми характерда, һәм ул, мәгариф оешмаларында белем алучыларның укудагы казанышларын исәпкә алып, хәбәрдарлык, коллегиальлек принциплары нигезендә үткәрелә.

Конкурс ике этапта үткәрелә:

читтән торып – мәгълүмати материаллар тапшыру;

турыдан-туры – гомуми белем бирү оешмасы коллективының педагогик һөнәри осталыгын үстерүгә юнәлдерелгән проектын яклау.

1.5. Грант алуга дәгъва кылучыларны конкурс нигезендә сайлап алуның читтән торып үткәрелә торган этабының критерие булып, түбәндәгеләрдән чыгып формалаштырыла торган, гомуми белем бирү оешмасының мәгариф эшчәнлеге нәтиҗәләренең суммар

күрсәткече тора:

белем бирүдә югары нәтиҗәләр күрсәткән гомуми белем бирү оешмалары рейтингы (алга таба – рейтинг);

Татарстан Республикасында «Россиянең ел укытучысы» һөнәри осталык конкурсларында дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмалары педагогларының катнашу нәтиҗәләре (соңгы өч ел эчендә муниципаль, зона һәм төбәк этаплары).

1.6. Рейтинг мәгариф эшчәнлегенең түбәндәге объектив күрсәткечләре нигезендә төзелә:

соңгы өч ел эчендә укучыларның Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасында (төбәк һәм йомгаклау этаплары) катнашуы нәтиҗәләре;

соңгы өч елда укучыларның республика мәктәп укучылары олимпиадасында катнашуы нәтиҗәләре;

соңгы өч елда укучыларның бердәм дәүләт имтиханнарын бирү нәтиҗәләре (белем бирү оешмасы сайлап алганча, өч гомуми белем бирү фәне буенча дәүләт имтиханнарының нәтиҗәләре исәпкә алына (динамикасы карала).

1.7. Рейтинг балларны кушу юлы белән булдырыла. Баллар түбәндәге тәртиптә исәпләнелә:

1 балл – Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасы төбәк этабының яки республика мәктәп укучылары олимпиадасының һәр призеры өчен;

3 балл – Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабында яки республика мәктәп укучылары олимпиадасында җиңгән һәр укучы өчен;

5 балл – Бөтенрооссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабының һәр призеры өчен;

10 балл – Бөтенросоия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында җиңгән һәр укучы өчен;

2 балл – «Россиянең ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының Татарстан Республикасындагы төбәк этабы муниципаль турының призеры өчен;

3 балл – «Россиянең ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының Татарстан Республикасындагы төбәк этабы муниципаль турында җиңүче өчен;

5 балл – «Россиянең ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының Татарстан Республикасындагы төбәк этабында катнашучы өчен;

6 балл – «Россиянең ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының Татарстан Республикасындагы төбәк этабының номинанты өчен;

7 балл – «Россиянең ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының Татарстан Республикасындагы төбәк этабының лауреаты өчен;

8 балл – «Россиянең ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының Татарстан Республикасындагы төбәк этабының призерлары (2, 3 урын) өчен;

9 балл – «Россиянең ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының Татарстан Республикасындагы төбәк этабының җиңүчеләре (1 урын) өчен;

10 балл – «Россиянең ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының Татарстан Республикасындагы төбәк этабының абсолют җиңүчесе өчен.

Укучыларның гомуми белем бирү фәннәре буенча олимпиадаларда максималь ирешелгән нәтиҗәләре исәпкә алына (һәр укучының нәтиҗәләре һәр фән буенча, максималь нәтиҗә нигезендә, бары бер тапкыр гына исәпкә алынырга мөмкин);

1.8. Мәгариф эшчәнлеге нәтиҗәләренең әлеге күрсәткечләре буенча алынган баллар кушыла. Гомуми белем бирү оешмалары рейтингта , балларның кимү тәртибендә, мәгариф эшчәнлеге нәтиҗәләренең суммар күрсәткече буенча урнаштырыла.

1.9. Конкурсның турыдан-туры этабында катнашу өчен мәгариф эшчәнлеге нәтиҗәләренең суммар күрсәткече буенча 1 дән 100 гә кадәр урын алган Грантка дәгъва кылучылар чакырыла.

1.10. Беренче этап йомгаклары буенча эксперт комиссиясе тарафыннан Конкурсның икенче этабында катнашуга хокуклы Грантка дәгъва кылучыларның бертигез (өстенлек

бирелмичә) исемлеге булдырылып, Республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

Республика конкурс комиссиясе Грантка дәгъва кылучыларны икенче этапка кертү турында карар кабул итә, ул, карар чыгарылган көнне, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтына урнаштырыла.

1.11. Грантка дәгъва кылучы Конкурсның беренче этабын үткәрү нәтиҗәләренә риза булмаган очракларда, Республика конкурс комиссиясенә апелляция тапшырырга хокуклы. Апелляция ирекле формада язмача рәвештә «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасының рәсми сайты («Грантлар» бүлегендә «Татарстан Республикасының уңышлы мәктәбе» бите) аша, Грантка дәгъва кылучыларны Конкурсның икенче этабына кертү турында Республика конкурс комиссиясе карары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылганнан соң исәпләнелә торган өч эш көне эчендә, Республика конкурс комиссиясе рәисенә тапшырыла.

1.12. Республика конкурс комиссиясе апелляцияне, аппеляцияләрне тапшыру срогы тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнелә торган ике көн эчендә, карап тикшерә. Республика конкурс комиссиясе экспертлар комиссиясе тарафыннан конкурс материалларын бәяләүдә кагыйдә бозулар булу-булмавын билгели, аның шулай ук бәяләү балларын нигезләү өчен экспертлар чакыру хокукы бар. Республика конкурс комиссиясе апелляцияне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

апелляцияне инкарь итү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне саклап калу турында;

апелляцияләрне канәгатьләндерү, грантка дәгъва кылучыны икенче этапка кертү һәм грантка дәгъва кылучыны икенче этапта катнашучылар исемлегенә кертү турында.

Республика конкурс комиссиясенең апелляция буенча карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар бертигез булган очракта, Республика конкурс комиссиясе рәисенең карары хәлиткеч була.

1.13. Апелляцияне карап тикшерү Республика конкурс комиссиясе тарафыннан беркетмә белән рәсмиләштерелә, беркетмәне комиссия утырышында катнашкан Республика конкурс комиссиясе рәисе һәм комиссиянең барлык әгъзалары имзалый.

1.14. Конкурсның турыдан-туры этабына читтән торып үткәрелгән этапта җыңгән һәр мәгариф оешмасыннан, мәктәп администрациясе, педагогик хезмәткәрләр, укучылар һәм ата-аналар җәмгыяте вәкилләрен кертеп, биш кешегә кадәрге составта команда җибәрелә, бу команда компьютерда тәкъдим итү рәвешендә эссе яклый:

а) «Уңыш, уңышлылык, уңышлы мәктәп – нәрсә ул?» дигән темага эссе.

Максаты: Уңышка ирешү технологияләрен формалаштыру сәләте.

Белем бирү оешмасының үсеш перспективасын күрү һәм аны алга таба камилләштерү өчен куллану осталыгын күрсәтү. Белем бирү оешмасының эшчәнлеге нәтиҗәлелеген анализлау сәләте.

Конкурс чарасының форматы: эссе тексты (5 биткә кадәр; шрифты – Times New Roman, кегле – 12, интервалы – 1,5, кырлары – 2 см).

Бәяләү критерийләре:

теле һәм мәгълүматларының камиллеге;

мәктәпнең миссиясен аңлау;

үз позициясен нигезләү осталыгы;

кыйммәт ориентирларының булуы;

бәян итүнең үзенчәлеге;

этика нормаларын үтәү.

б) компьютерда презентация, анда эсседа бәян ителгән нигезләмәләр, «Уңышлы мәктәп» буларак билгеләү мөмкинлеген бирү өчен, белем бирү оешмасының теге яки бу эшчәнлегендә конкрет уңышларга ирешүен чагылдыра торган рәвештә гамәлдә күрсәтелә.

Максаты: белем бирү оешмасының теге яки бу эшчәнлеге өлкәсендә казанышларын конкрет мисаллар ярдәмендә күрсәтү. Белем бирү оешмасы эшчәнлегенең тәҗрибәсе белән таныштыру һәм анализлауга сәләтен күрсәтү. Конкрет белем бирү оешмасына хас булган кыйммәт ориентирларын билгеләп, аларны күрсәтү осталыгы.

Конкурс чарасының форматы: PowerPoint компьютер презентациясе: күләме – 5 биткә кадәр аңлатма язуы белән 15 слайдка кадәр, (шрифты – Times New Roman, кегле – 12, интервалы – 1,5, кырлары – 2 см).

Бәяләү критерийләре:

мәктәпнең уңышка ирешүдәге методикалары һәм технологияләренең үзенчәлекле булуы;

мәктәпнең уңышлы эшләвен күрсәтүнең бөтенлеге;

нәтиҗәлелеге һәм тәҗрибәне гамәли тарату;

үзенчәлеге һәм инновациялелеге;

мәгълүмати культурасы;

үз-үзен бәяләүнең объективлыгы;

мәгариф эшчәнлегендә барлык катнашучыларның берлектә эшләвен һәм хезмәттәшлек итүен күрсәтү;

мәктәпнең кыйммәт ориентирлары (миссиясе) белән таныштыру;

мәктәпнең уңышка ирешүендә системалы эшчәнлектән һәм интерактив ысуллардан файдалану.

Барлык сайлап алу материаллары Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (алга таба – «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасы) рәсми сайтларында «Грантлар» бүлегенә урнаштырыла.

1.15. Турыдан-туры этап педагогик коллективның педагогик осталыгын һөнәри үстерүгә юнәлдерелгән проектны яклау формасында үткәрелә.

1.16. Проектны яклау, презентация рәвешендә (кәгазьдә һәм электрон туплагычта) гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

1.17. Проектны яклауга, күп дигәндә, 10 минут вакыт бирелә.

1.18. Турыдан-туры этапның конкурс нигезендә сайлап алу критерийләре түбәндәгеләр:

гомуми белем бирү оешмасы алдына куелган бурычлардан чыгып, тәкъдим ителә торган эшләнмәнең актуальлеге, яңалыгы, максатка ярашлылыгы;

тәкъдим ителгән проектның нәтиҗәлелеге, аңа карата ихтыяҗның булуы, тормышта киң файдалану (тиражлау) мөмкинлеге;

проектны тормышка ашыру өчен башлангыч базаның булуы;

социаль партнерларның булуы;

проектны гамәлгә ашыруның конкрет нәтиҗәләрен фаразлау һәм аны гамәлгә кертүне бәяләү механизмының булуы;

проектның технологиялелеге.

1.19. Конкурс нигезендә сайлап алуның һәр критерие буенча максималь балл – 10 балл.

Баллар һәр критерий буенча исәпләнелә һәм кушыла.

1.20. Татарстан Республикасында «Уңышлы мәктәп» гранты мәгариф эшчәнлеге нәтиҗәләренең һәм проектны яклау нәтиҗәсенең суммар күрсәткече буенча 1 дән 21 гә кадәр урын алган гомуми белем бирү оешмаларына бирелә.

Грант алучылар Республика конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнеп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

1.21. Конкурста катнашуга электрон рәвештә заявкалар тапшыру өчен оператор булып «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасы тора.

1.22. Грантка дәгъва кылуга Конкурста катнашу чорында һәм Грантны тормышка ашыру чорында, директор турында белә торып дөрес булмаган яки ялган мәгълүматлар ачыкланганда, Грант бирү турында карар кабул ителми.

## II. Конкурста катнашуга заявка тапшыру

2.1. Грантка дәгъва кылучыга «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасының рәсми

сайты («Грантлар» бүлеге, «Татарстан Республикасының уңышлы мәктәбе» бите) аша, 2016 елның 15 июненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитетының мәгариф идарәсе (бүлек) җитәкчесе раслаган заявканы тапшырырга кирәк.

2.2. Заявканы 2016 елның 15 июненнән соң тапшыру очрагында Грантка дәгъва кылучы конкурста катнашу хокукыннан мәхрүм кала.

## III. Конкурсны үткәрү тәртибе

3.1. Грантны дәгъва кылуга конкурс Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә үткәрелә.

3.2. Грант бирүче заявкаларны кабул итү вакыты тәмамланырга кимендә 10 эш көне кала Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында һәм «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасы сайтында мәгълүмат урнаштыру юлы белән Конкурс үткәрү турында игълан итә.

3.3. Грантка дәгъва кылучылар 2016 елның 15 июненә кадәр «ТР мәгарифне үстерү институты» оешмасының рәсми сайты («Грантлар» бүлеге, «Татарстан Республикасының уңышлы мәктәбе» бите) аша Грантта катнашуга заявка тапшыра.

3.4. Конкурс материалларын һәм проектны яклауны бәяләү өчен 11 кешедән торган Республика конкурс комиссиясе һәм 20 кешедән торган экспертлар комиссиясе төзелә.

3.5. Республика конкурс, экспертлар комиссияләре утырышлары кирәк булуга карап үткәрелә һәм составының яртысыннан артыграгы катнашкан очракта, хокуклы санала.

3.6. Утырышта катнашучыларның күпчелеге тавыш биргән очракта, Республика конкурс комиссиясе карарлары кабул ителгән дип санала. Тавышлар бертигез булганда, Республика конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

3.7. Грант алуга конкурсны оештыру-методик яктан тәэмин итү һәм үткәрүне рәис, җаваплы сәркатиб, матбугат секретаре һәм әгъзалардан торган Республика конкурс комиссиясе хәл итә.

3.8. Республика конкурс комиссиясенең персональ составы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

3.9. Республика конкурс комиссиясе:

массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысуллар белән Конкурсны үткәрү шартлары, тәртибе һәм сроклары турында игълан итә;

катнашучылардан заявкалар һәм материаллар кабул итә;

экспертлар комиссиясен төзи;

Грант алуга тапшырылган материалларга бәйсез экспертиза оештыра;

Конкурсның беренче (читтән торып) һәм икенче (турыдан-туры) этапларын үткәрүне оештыра;

апелляцияләрне карап тикшерә;

Конкурсның беренче (читтән торып) һәм икенче (турыдан-туры) этапларына йомгак ясый;

Конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыра;

Конкурс йомгакларын һәм иң яхшы материалларны бастырып чыгаруны оештыра.

3.10. Конкурс материалларын бәяләү өчен рәисе һәм әгъзаларыннан торган экспертлар комиссиясе булдырыла.

3.11. Экспертлар комиссиясенең персональ составы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

3.12. Конкурс материалларына экспертиза үткәргәндә, экспертлар комиссиясе эшенә бәйсез экспертлар җәлеп ителергә мөмкин.

3.13. Экспертлар сыйфатында түбәндәгеләрнең вәкилләре җәлеп ителергә мөмкин:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

педагогик хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүнең төбәк оешмалары;

югары һөнәри белем бирү оешмалары;

җәмәгатьчелек.

3.14. Конкурс материалларына экспертиза үткәрелгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

тапшырылган материалларны бәяләү критерийләре нигезендә бәяләүнең объективлыгы;

яшеренлелек (шул исәптән конкрет катнашучыны бәяләүгә җәлеп ителмәгән экспертлар комиссиясе әгъзаларына карата).

3.15. Грант алуга конкурсның икенче (турыдан-туры) этабында катнашучыларны бәяләү, бәяләү критерийләре нигезендә, экспертлар бәяләмәсе ысулы белән экспертлар комиссиясе әгъзалары тарафыннан башкарыла.

3.16. Экспертлар комиссиясе:

билгеләнгән срокларда, бу Нигезләмәдә билгеләнгән критерийләр нигезендә, читтән торып үткәрелгән һәм турыдан-туры этапларда Грантка дәгъва кылучыларның конкурс материалларын һәм хезмәтләрен бәяли;

баллар эксперт кәгазьләренә язып куела, эксперт имзасы белән расланып, экспертлар комиссиясе рәисенә тапшырыла;

эксперт кәгазьләре нигезендә, Грантка дәгъва кылучыларның рейтингы формалаштырыла; Экспертлар комиссиясе рәисе һәм әгъзалары имзалаган рейтинг Республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

3.17. Экспертлар комиссиясе 2016 елның 20-24 июнендә тапшырылган заявкаларны карап тикшерә, Грантка дәгъва кылучыларның читтән торып үткәрелгән этаптагы хезмәтләренә экспертиза ясый.

3.18. Экспертлар комиссиясенең эш йомгаклары буенча, Конкурсның турыдан-туры этабында катнашу өчен Конкурсның Грантка дәгъва кылучыларның исемлекләре раслана.

3.19. Конкурсның турыдан-туры этабы Казан шәһәрендә 2016 елның 4-9 июлендә үткәрелә. Экспертлар комиссиясенең эш йомгаклары буенча, Грантка дәгъва кылучылар рейтингы булдырылып, Республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

3.20. Республика конкурс комиссиясе Конкурсның турыдан-туры этабы йомгаклары буенча 2016 елның 11-15 июлендә Грант алучылар исемлеген төзи.

3.21. Грант бирүче 2016 елның 20 июленә кадәр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында Грант алучыларның расланылган исемлеген урнаштыра: htpp//: mon.tatar.ru/ «Укытучыларга грантлар»/ «Татарстан Республикасының уңышлы мәктәбе» бүлеге.

## IV. Конкурсны финанслау

4.1. Конкурсны оештыру һәм үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының җыелма сметасында күздә тотылган акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.

4.2. Грантны тормышка ашыруга субсидия, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә.

4.3. Субсидия күчерүгә нигез булып Грантны гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән субсидия алучы – гомуми белем бирү оешмасы тарафыннан төзелә торган килешү тора.